ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**03.04.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 741**

«2018 елга Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2017 елның 30 декабрендәге 3328 номерлы ЗМР БК карарына өстәмәләр кертү хакында

«2018 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2017 елның 08 сентябрендәге 641 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча, «Адреслылык принцибын саклау һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычыннан чыгып социаль яклау чараларын бирүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законына,Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 14 февралендәге 181-ФЗ номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2018 елга Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2017 елның 30 декабрендәге 3328 номерлы Башкарма комитет карарын түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:

5.П. Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба - ЕГИССО) файдалану юлы белән һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын бирү турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан мәгълүмат тапшыруны тәэмин итәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2018 елга Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2017 елның 30 декабрендәге 3328 номерлы карарының 5 пунктын 6 пункт дип санарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин